

Узган шимбәдә Кадошкино районы 20 кешелек Насакан Потьма авыл vзәгенен бер почмагында зур, якты бәйрәм узды.
Архив язмаларында Насакан Потьма дип 1912 нче елны атала башлаган. Ул икмәк-тозлы, тарихка, традицияләргә, тырыш кешеләргә бай. Безнен жирдә чын эшчеләр, патриотлар яши. Һәм нәкъ менә алар тарихны бизәп тора.      Якты тосләр, кvнелле эмоцияләр, шатлыклы хисләр, елмаюлар, бәхетле йозләр, яхшы очрашулар, жылы кул кысышулар һәм кочаклашулар! Бу конне егермеләп кеше жыелган иде. Бәйрәмдә авыл халкы һәм тирә-якта яшәvче туганнар, кvршеләр катнашты. Әйтеп китәргә кирәк, берничә фамилия остенлек итә бу кечкенә аваылда. Кунаклар арасында да, гаиләләре белән Асаиновлар, Альмяшевлар, Агишевлар, Алдаркиналар, Байбековалар, Дербердеевлар, Донскойлар, Иштрякова, Капкаевлар, Мусякаевлар бар иде. Авылнын олы кешеләре дә читтә калмады; Зәкәрия кызы Нурия Еналеева белән Абдулла кызы Нурия Альмяшева бәйрәмгә ямь остәделәр.Бәйрәм булгач, матур сvзләр янгырады, тирән истәлекләр кvнелләрне тибрәтте, татар халык койләре vз тынлаучыларын истәлекләргә, еракка алып киттеләр һәм шул вакытта халык кvнеле мон белән тулды. Аннары авыл койләре, такмаклар кvнелне ачты. Бәйрәмнен яшь кунаклары «тыныч уеннар территориясендә» урнаштылар.
Бәйрәм һәрбер Насакан Потьма кешесенен кvнел тvрендә матур хатирә булып уелып калды.